# Көз бәйрәме.

Алып баручы: Балалар,без  бүген көзге бәйрәмгә җыелдык. Карагыз әле, безнең залны, ничек матур бизәлгән. Әйтерсең лә алтын көз үзенең сары, кызгылт яфракларын безнең залга кертеп тутырган. Менә идәндә нинди матур яфраклар ята.

1-нче бала: Ни арада җәй үтте

Алтын көз килеп җитте.

Шатлык  тулы бу бәйрәмне

Балалар күптән көтте.

2-нче бала: Көз көннәре килеп җитте

Хушлашабыз җәй белән.

Бөтен җиргә яфраклардан

Алтын келәм җәелгән.

3-нче бала: Көннәр инде салкынайды

Кышлар бераз якынайды.

Тирә-юнь ил сары төстә

Әллә соң бу алтын ай мы?

Җыр: “Яфраклар бәйрәме”.

Музыка астында Көз керә.

Көз: Ерактан тавыш ишетеп

Сезнең янга килдем мин

Исәнмесез, балалар

Күрәм, бүген сездә бәйрәм

Ә сез беләсезме, мин кем булам?

Балалар:  Көз.

Алып баручы: Исәнме көз, исенме көз!

Көттек без килүеңне.

Бүген, бүген, бүген, бүген

Яфракларның бәйрәме.

Балалар урындыкка утыралар.

Көз: Ашыгып сезнең янга

Килдем мин нәни дуслар

Минем бүген туган көнем

Көтәм сезден бүләкләр.

Тиенчекләр: Без тиен-тиенкәйләр

Сикергәләп йөрибез

Чикләвекләр җыеп сиңа

Бүләк итеп бирәбез.

Аюлар:



Аюлар: Ә без нәни аюлар

Сиңа бал алып килдек

Чәй янына кура җиләк

Менә сиңа бездән бүләк

Синең бит туган көнең.

Керпе (1): Туган көнеңә бүләккә,

Җыйдык без тәмле алма

Без урман керпеләре

Сиңа исәнле телибез.

Керпе (2): Гөмбә җыярга теләдек,

Бик озак әзләдек,

Әзли – әзли тапмадык.

Алып баручы: Балалар, килегез, гөмбәләрне җыегыз әле.

Җыр “Грибы” ( на русском языке).

Алып баручы: Туган көндә бүләкләр

Кабул итү күңелле.

Әйдәгез, бергәләп җырлап алыйк.

Көзне шатландырыйк.

Җыр “Алтын көз”.



Көз:  Шундый матур җырладыгыз

Күңелле бәйрәмегез

Әйдәгез инде, балалар, биеп тә күрсәтегез.

Парлы бию.

Көз: Мин үзем генэ килмәдем

Минем бар бит дусларым

Алтын-сары яфракларым

Сез алар белән уйнагыз.

Уен “ Кайсы агачның яфрагы?”,



(Көз яфраклар бирә һәм уен тәкъдим итә “Листики – листочки”,

Көз: Мин балалар кунак көтәм

Яңгырларны яратам

Әйдәгез бергә каршылыйк

Күңелләрне күтәрик.

Яңгырлар: Без килдек туган көнеңә

Без яңгыр тамчылары

Бүләк итәбез сиңа җыр.

Яңгыр турында: “Тамчылар”. (урындыклар янына басып).

Бию зонтиклар белән.

Көз: Булдырдыгыз, балалар.

Ишек шакыйлар.

Алып баручы: Керегез, кер, кем бар анда?

(Уңыш бабай керә)

Уңыш бабай: Исәнмесез, балалар!

Мине таныйсызмы соң?

Балалар: Юк

Уңыш бабай: Ә сез әйбәтләбрәк карагыз,

Менә минем киемнәрем нинди.

Нинди рәсемнәр бар

Минем киемнәремдә?

Алып баручы: Белдем, белдем, дуслар

Бу бит Уңыш бабай.

Карале, Уңыш бабай, Көз, без бит яшелчәләр үстердек.

(Маска кигән балалар чыгып басалар).

Уңыш бабай: Дуслар, бәйрәмгә килгәнсез

Гөлдәй матур киенгәнсез

Сезниләр китердегез көзгә

Сөйләп бирегезче безгә.

Кәбестә: Безнең бакча балалары
Яшелчәләр үстерә
Бакчадагы туптан да зур
Мәсәлән, "мин кәбестә".

Кабак: Карагыз әле, бер генә
Менә, миңа, кабакка
Турап куйсагыз
Мин сыймыйм
Хәттә тугыз табакка.

Бәрәңге: Ә бәрәңге, бәрәңге
Бәрәңгене күр әле
Сап – сары бәрәңге белән
Тирән базыбыз тулды.

Кишер: Көчле, җитез булыйм дисәң,
Кишер ашап кара син
Кишер саулык чыганагы
Кишердә күп каротин.

Суган: Ә мин суган. Әрчегәндә
Килсә дә яшь күзегезгә
Мине ашасагыз әгәр
Суык тимәс үзегезгә.

Чөгендер: Мин чөгендер
Мин дә кирәк

Кешеләргә ашар өчен

Борщ пешерер өчен

Һәм винегрет ясар өчен.

Помидор: Ә мин булам помидор

Төп яшелчә салатта

Тәмле генә түгел әле

Витамин күп томатта

Уңыш бабай: Балар, барыгызны да бакчага уңыш җыярга яшәм.

Әйдәгез, бергәләп җырлап – биеп алыйк.

Хороводная – огородная.

Уңыш бабай: Менә, дуслар, күпме уңыш җыелды. Ә хәзер әйдәгез әле шушы яшелчә һәм җиләк – җимешләрдән борщ һәм компот пешерәбез.

Уен "Аш һәм компот пешерү",

Көз: Балалар, яшелчәләрдә бик күп витамин. Шуңа күрә аларны ашарга кирәк. Менә мин дә сезгә винегрет ясап алып килдем. Авыз итәрсез.

Алып баручы: Ә хәзер, балалар, әйдәгез әле Көзгә " Ак калачны" җырлыйбыз. Көзнең бит туган көне.

"Ак калач" җырын җырлыйлар.

Көз: Барыгызны да яратам

Һәм бүләкләр таратам.

(Разноста җиләк – җимешләр)

Сау булыгыз!

